## ДӨНЬЯ БИТ УЛ...

Илгиз Йомагуҗин көе
(Радмир Туйсин репертуарыннан)

Дөнья бит ул, дөнья бит ул
Миннән соң да, беләм, калыр.
Мең ел яшәп йолдызлар да
Тәүдә балкыр,азак янар.
Юл күрсәтер адашканга,
Азак күмер булып калыр.

Дөнья бит ул, дөнья бит ул,
Миннән соң да, беләм, калыр.
Дөнья авыр, ләкин матур
Хушлашуы булыр авыр.
Шунысы бик жәл, миннән соң дим
Бетермәгән эшем калыр.

Дөнья бит ул, дөнья бит ул
Миннән соң да, беләм, калыр.
Ришвәт биреп калып булмый,
Бер көн,беләм, килер әҗәл.
Ярдәмемә мохтаҗ булып
Кемдер калыр, шунысы бик жәл.

## ӨЗЕП АЛ

Нәфисә Хәкимова көе
(Хәния Фәрхи репертуарыннан)

Юлларыңа чәчәк булып үстем.
Өзеп ал син мине, өзеп ал!

Һич калдырма юллар тузанында -
Йөрәгеңә сөю итеп сал!

*Кушымта:*
Мин – сөю бу тормыш языңның,
Иң матур, иң гүзәл саф гөле.
Мин – синең шатлыгың, бәхетең,
Өз, ярым, өз син мине!

Урап үтмә инде мине, җаным,
Чит-ятлар кулына ташлама.
Бәхет өчен килдек бу дөньяга,
Гомер язым яңа башлана.

*Кушымта.*

Үз итмәсәң мине, яр итмәсәң,
Ялгызымны утта яндырма.
Кайнар кулларыңда үләрмен мин,
Кырауларга, зинһар, калдырма.

*Кушымта.*

Болыннарда, җаным, чәчәкләр күп,
Сайлаганнар, әйдә, сайласын.
Башкаларны өзсәң, тик соңыннан
Үкенерлек булып калмасын!

*Кушымта.*